Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Кубас авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

14.12.2023 ел № 38\2

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Кубас авыл җирлеге Советының
2022 елның 27 октябрендәге
«Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Кубас авыл җирлеге Советы депутаты статусы
турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы
26/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кубас авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Кубас авыл җирлеге Советының 2022 елның 27 октябрендәге 26/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Кубас авыл җирлеге советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәнең 3 статьясының 3 пунктына, 18 статьясындагы 1 пунктының «б» пунктчасына, «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе) сүзләре белән алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Кубас авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Кубас авыл
җирлеге башлыгы Логинова Н.С.